| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ИВАНОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИВАНОВКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30 октябрь 2020 ел № 2

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Ивановка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлеге Уставы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Ивановка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 15 ноябренә 13 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Ивановка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, тыл хезмәтчәннәреннән, өч һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган күп балалы гаиләләрдән, сиксән яшьтән өлкәнрәк гражданнардан һәм көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 500 сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме?:

I. Җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту:
- Ивановка авылында (Яшьлек урамы, Энтузиастлар урамы, Үзәк урам) юлларына вак таш җәю;);
- үлән чабу;
- Ивановка (Үзәк, Октябрь, Яшьлек, Заречная, Нагорный, Энтузиастлар, Родничная, Мәктәп тыкрыгы) авылындагы юлларны кардан чистарту .

II. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- Октябрьская һәм Молодежная урамнары буенча (уң як) суүткәргечне ремонтлау.

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Ивановка авылы, Яшьлек урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл җирлеге администрациясе бинасындагы мәгълүмат стендында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы
«Ивановка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.П.Бодряева